СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

28.06.2024 № 47/7

На №__________от______________

**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2007 елның 27 апрелендәге 13/9 номерлы карары белән (2011 елның 1 июнендәге үзгәрешләр белән) расланган Тукай муниципаль районы дәүләт милкендәге һәм муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен бирү тәртибе турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 312-ФЗ номерлы Федераль закон, район Уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2007 елның 27 апрелендәге 13/9 номерлы карары белән (2011 елның 1 июнендәге үзгәрешләр белән) расланган Тукай муниципаль районы дәүләт милкендәге һәм муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 8.2 пунктының 6 абзацын түбәндәге редкциядә бәян итәргә:

«Палата гариза һәм әлеге пунктта күрсәтелгән кирәкле документлар алынган датадан ундүрт эш көне эчендә мондый җир кишәрлеген милеккә бирү яки аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итәргә тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (https://tukay.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы,
Совет Рәисе урынбасары

Р.И. Закиров